Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге составына керүче
Бәтке авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

29 октябрь 2019 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 13 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Бәтке һәм Киек авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Бәтке авылы Тынычлык урамы, Яншык авылы Мәктәп урамы, Кече Укмас авылы Пионер урамы юллары ремонты өчен;
- Кече Укмас авылы Гагарин урамы суүткәргеч челтәренә материаллар сатып алу өчен;
- Бәтке һәм Яншык авыллары зиратын әйләндереп алу өчен материаллар алуга;
- кышкы чорда Бәтке авылы җирлегендә юлларны карап торуга

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 173 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 126 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
“ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 124 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге составына керүче Бәтке авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Бәтке һәм Киек авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Бәтке авылы Тынычлык урамы, Яншык авылы Мәктәп урамы, Кече Укмас авылы Пионер урамы юллары ремонты өчен;

- Кече Укмас авылы Гагарин урамы суүткәргеч челтәренә материаллар сатып алу өчен;

- Бәтке һәм Яншык авыллары зиратын әйләндереп алу өчен материаллар алуга;

- кышкы чорда Бәтке авылы җирлегендә юлларны карап торуга

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Бәтке авылы,Ленин урамы, 4 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы,23 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Ф.М.Динмөхәмәтов

Бәтке авыл җирлеге башлыгы: Ф.М.Динмөхәмәтов